МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ
«ЯҢА АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
IV ЧАКЫРЫЛЫШ

X СЕССИЯ

КАРАР № 1

Яңа Александровка авылы 2021ел,17 июнь

Яңа Александровка авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 14 нче февралендә узган 56нчы сессиясенең 2 нче карары –"Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә"гә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2.03.2007 ел, № 25-ФЗ Федераль законга, муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, №50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексына туры китерү максатларында

Яңа Александровка авыл җирлеге Советы
Карар:

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында " Яңа Александровка авыл җирлеге Советының 2 56 сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 13 статьяда:

- 5 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

5) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Яңа Александровка авыл җирлеге
башлыгы **Е.Г.Гыйрфанова**